КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 сентябрь г.Казань № 680

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 гыйнвар, 9 нчы; 2016 ел, 15 август, 565 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 648 нче; 2017 ел, 21 март, 171 нче; 2017 ел, 31 май, 327 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктта:

унтугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норма чыгару эшчәнлеген координацияләү (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тикшерүдә тоту) (02.04.01<*>);

республика башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03<*>).»;

4.1 пунктка түбәндге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«террорчылыкка каршы тору чараларын гамәлгә ашырганда укулар үткәрүдә катнаша;

Дәүләт комитетына беркетелгән объектларны (территорияләрне) террорчылыкка каршы саклау таләпләрен үтәүне оештыра һәм тәэмин итә.»;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.5 пункт өстәргә:

«5.5. Дәүләт комитетын үзгәртеп төзегәндә архив документлары (идарә итү, финанс-хуҗалык, шәхси состав буенча документлар, вакытлы саклау срогы булган документлар) тәртипкә салынып, хокук варисына тапшырыла.

Дәүләт комитеты бетерелгәндә Татарстан Республикасы архив фонды докментлары, шәхси состав буенча документлар, шулай ук саклау вакытлары чыкмаган документлар тәртипкә салынып, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә саклануга тапшырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин